ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕН КҮЗӘТҮ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ | БОЕРЫК

__21.07.2017___ Казан ш. № ___54_____

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибе турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 3 пункты нигезендә

**Б О Е Р Ы К Б И Р Ә М:**

1. Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелүнең кушымтада бирелгән тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык В.А. Кудряшов

ТР ДТК инспекциясенең
21.07.2017 № 54
боерыгы белән
расланды

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә Татарстан Республикасы
дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә
итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә
катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары
составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибе

1. Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекцмясендә (алга таба – Инспекция) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибе (алга таба – Тәртип) «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 3 пунктына нигезләнеп эшләнде.

Әлеге Тәртип эш бирүче тарафыннан Инспекциядә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә (алга таба – граждан хезмәткәрләре) иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәте (алга таба – коммерциячел булмаган оешма) белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү процедурасын регламентлый.

Әлеге Тәртип Инспекциядә аларны эшкә алучының вәкиле булып Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе башлыгы (алга таба – Инспекция башлыгы) торган Татарстан Республикасы граждан хезмәткәрләренә кагыла.

2. Коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү турында гариза (алга таба – Гариза) граждан хезмәткәре тарафыннан язмача, шушы Тәртипкә 1 нче кушымтада бирелгән формада төзелә.

3. Граждан хезмәткәре Гаризаны коррупциячел һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба – Җаваплы зат) тапшыра.

4. Җаваплы зат Гаризаны кергән көнендә шушы Тәртипкә 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча Журналда терки.

5. Җаваплы зат Гаризаны алдан карау эшен гамәлгә ашыра һәм аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли.

Гаризаны алдан карау барышында Җаваплы зат Гаризаны тапшырган граждан хезмәткәреннән коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуының планлаштырылган функцияләрен билгеләүче язмача аңлатмаларны һәм документларны сорарга хокуклы.

Бәяләмәдә граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирү яисә рөхсәт бирүдән баш тарту турында тәкъдим булырга тиеш.

6. Гариза теркәлгән көннән соңгы биш эш көненнән дә соңга калмыйча Җаваплы зат Гаризаны, Бәяләмәне һәм башка материалларны (булган очракта) теркәп, коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирү яисә рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен Инспекция башлыгына (аның вазыйфаларын башкаручы затка) карау өчен тапшыра.

Инспекция башлыгы (аның вазыйфаларын башкаручы зат) Гаризаны алган көннән соң ике эш көне эчендә карар кабул итә.

7. Җаваплы зат Инспекция башлыгы (аның вазыйфаларын башкаручы зат) карар кабул иткән көннән соңгы ике эш көне эчендә граждан хезмәткәренә Гаризаны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм аңа Гаризаның дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте буенча бүлек мөһере белән таныкланган, Инспекция башлыгының резолюциясе куелган күчермәсен кул куйдыртып тапшыра. Инспекция башлыгы резолюциясе куелган Гаризаның төп нөсхәсе граждан хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлә.

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республика-сы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә Татарстан Респуб-ликасы дәүләт граждан хезмәт-кәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибенә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе башлыгы В.А. Кудряшовка

______________________________
(Ф.И.А.,
______________________________
биләнә торган вазыйфа һәм структур
______________________________
бүлекчә, яшәгән урын адресы
______________________________
телефон номеры)

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү турында

ГАРИЗА

Миңа (кирәклесенең астына сызарга)____________________________________
(иҗтимагый оешманың,
_____________________________________________________________________________
торак, торак-төзелеш, гараж кооперативының, яшелчәчелек, бакчачылык,
_____________________________________________________________________________
дача кулланучылар кооперативының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең аталышы)
______________________________________________сыйфатында түләүсез нигездә
_______________________________________________________________________белән
(бер кеше кулындагы башкарма органның яисә идарә коллегиаль органының аталышы)
идарә итүдә катнашырга, аның идарә коллегиаль органы составына керергә рөхсәт бирүне сорыйм.

| | | |
|---|---|---|
| _______________ | _________________ | _______________________ |
| (дата) | (имза) | (фамилия, инициаллар) |

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республика-сы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә Татарстан Респуб-ликасы дәүләт граждан хезмәткә-ренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибенә
2 нче кушымта

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирелү турында гаризаларны теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Дата | Үтенеч язуын бирүченең Ф.И.А., вазыйфасы | Үтенеч язуын бирүченең имзасы | Теркәүченең Ф.И.А. | Теркәүченең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |